**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнары Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру, шулай ук мониторинг уздыруга вәкаләтле органның коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча башка дәүләт органнары белән мәгълүмати хезмәттәшлеген тәэмин итү буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг оештыру һәм үткәрү чаралары турында» 2011 елның 23 мартындагы ПУ-148 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 4 июнендәге ПУ-523 номерлы, 2018 елның 25 августындагы ПУ-586 номерлы һәм 2021 елның 12 апрелендәге ПУ-284 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), преамбулада «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең законнар чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 18 статьясындагы 7 пунктның «д$^1$» пунктчасы белән» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектлары гавами хакимиятен оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 3 пункты белән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында агач материалларын законсыз әзерләүне, транспортлауны, эшкәртүне, сатуны һәм экспортлауны кисәтү һәм туктату мәсьәләләре ведомствоара комиссиясе турында» 2012 елның 16 маендагы ПУ-342 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 4 мартындагы ПУ-233 номерлы, 2017 елның 6 октябрендәге ПУ-888 номерлы, 2018 елның 16 мартындагы ПУ-236 номерлы, 2019 елның 6 августындагы ПУ-451 номерлы, 2020 елның 8 июлендәге ПУ-387 номерлы, 2021 елның 18 июнендәге ПУ-490 номерлы һәм 2023 елның 21 гыйнварындагы ПУ-43 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында агач материалларын законсыз әзерләүне, транспортлауны, эшкәртүне, сатуны һәм

экспортлауны кисәтү һәм туктату мәсьәләләре ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында судагы биологик ресурсларны саклау мәсьәләләре буенча республика советы турында» 2016 елның 4 ноябрендәге ПУ-985 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1090 номерлы, 2017 елның 20 октябрендәге ПУ-915 номерлы, 2018 елның 14 маендагы ПУ-370 номерлы, 2019 елның 19 мартындагы ПУ-174 номерлы, 2019 елның 11 июлендәге ПУ-396 номерлы, 2020 елның 18 апрелендәге ПУ-240 номерлы, 2020 елның 12 августындагы ПУ-482 номерлы һәм 2021 елның 5 октябрендәге ПУ-792 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасында судагы биологик ресурсларны саклау мәсьәләләре буенча республика советы турында нигезләмәдә:

7 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Советның Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары кабул ителүне таләп итә торган тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йөкләмәләре һәм карарлары проектлары рәвешендә рәсмиләштерелә. Әлеге проектларга Совет рәисе имза куя һәм карап тикшерү һәм карар кабул итү өчен алар тиешенчә Татарстан Республикасы Рәисенә, Татарстан Республикасы Премьер-министрына юллана.»;

б) Татарстан Республикасында судагы биологик ресурсларны саклау мәсьәләләре буенча республика советы (алга таба – Совет):

Совет составыннан И.В. Герасимованы, А.П. Костинны, О.В. Назаровны, И.Ш. Ханбиковны чыгарырга;

Совет составына Артемьев Артем Викторовичны – Су ресурслары федераль агентлыгы Түбән Идел су бассейны идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы буенча су ресурслары бүлеге башлыгын (килешү буенча) кертергә;

Совет әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Е.В. Коробченконың – «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының җир асты байлыкларыннан файдалану, табигать

ресурслары һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы урынбасары»;

М.А. Шинкаревның – «Балыкчылык буенча федераль агентлыкның Урта Идел территориаль идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы буенча судагы биологик ресурсларга дәүләт контроле, күзәтчелек һәм аларны саклау бүлеге башлыгы (килешү буенча)».

4. Татарстан Республикасы Президентының «Илкүләм проектларны һәм дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә объектларны төзүне, яңартуны, капиталь төзекләндерүне тәэмин итү буенча координация штабы оештыру турында» 2021 елның 3 декабрендәге ПУ-922 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Илкүләм проектларны һәм дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә объектларны төзүне, яңартуны, капиталь төзекләндерүне тәэмин итү буенча координация штабы турында нигезләмәнең 3 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) Илкүләм проектларны һәм дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә объектларны төзүне, яңартуны, капиталь төзекләндерүне тәэмин итү буенча координация штабы (алга таба – Штаб) составында:

Штаб составыннан А.Ә. Кәримовны, Т.Р. Минушевны, М.Н. Садыйковны, Т.Җ. Сөләймановны чыгарырга;

Штаб составына кертергә:

Аманов Рөстәм Ринат улын – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының икътисадый куркынычсызлык һәм коррупциягә каршы көрәшү идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Коробченко Олег Владимировичны – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрын;

Миңнуллин Марсель Мансур улын – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрын;

Садыйков Ринат Наил улын – Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрын;

Штаб әгъзасы Р.Н. Миңнехановның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Рәисе, Штаб рәисе».

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 14 апрель
№ 234